# ТҮБӘН ҮРӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

15 июнь 2022 ел №19

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турындагы кодексы, кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында төзелгән килешүләр нигезендә Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында кушып бирелгән нигезләмәне расларга.
2. Түбән Үрәс авыл җирлеге Советының «Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 4 апрелдагы 10 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Үрәс авыл җирлеге
башлыгы урынбасары: Гордеева Г.И.

Түбән Үрәс авыл җирлеге Советының 2022 елның 15 июндагы 19 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турындагы нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча Бердәм комиссия (алга таба – Конкурс комиссиясе) составы, эш сроклары һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру методикасы билгеләнә.

1.2. Конкурс 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның (алга таба - Федераль закон) 17 статьясы һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 20 статьясы нигезендә үткәрелә.

Конкурс муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъвачыларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Җирлекнең җирле үзидарә органы Кукмара муниципаль районы Советына вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрү турында үтенеч белән мөрәҗәгать, муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы һәм аны биләүгә квалификация таләпләре турында мәгълүмат җибәрә. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс Кукмара муниципаль районы Башлыгы карары белән игълан ителә.

1.4. Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.5. Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрелми:

1) сайланулы муниципаль вазыйфаны биләүче затның вәкаләтләрен үтәүне турыдан-туры тәэмин итү өчен гамәлгә куела торган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куйганда;

2) вакытлы хезмәт шартнамәсе төзегәндә;

3) җирле үзидарә органы юкка чыгуга, аның штаты кыскаруга, җирле үзидарә органы структурасы үзгәрүгә бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына билгеләп куйганда;

4) муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы өлкән, кече вазыйфалары төркеменә караган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куйганда;

5) кадрлар резервында торучы муниципаль хезмәткәрне (гражданны) муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куйганда.

1.6. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

Россия Федерациясе гражданнарынын муниципаль хезмәткә аларның сәләтләре һәм профессиональ әзерлеге нигезендә бертигез дәрәҗәдә керүенә конституциячел хокукын, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукларын тәэмин итү;

муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә иң туры килә торган, Феде-

раль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми санынннан кандидатларны сайлап алу.

1.7. Конкурслар үткәргәндә хәл ителә торган бурычлар:

конкурс биремнәрен һәм процедураларны үтәгәндә барлык кандидатлар өчен тигез шартлар тәэмин итү;

кандидатларны объектив һөнәри әһәмияткә ия критерийлар нигезендә бәяләү;

конкурста катнашучылар арасыннан конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезләнгән күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары таләпләренә туры килә торган затларны билгеләү.

1.8. Кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

1.9. Конкурста катнашуга кертелмәгән муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва итүчеләрнең һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары аларга конкурс тәмамланганнан соң өч ел эчендә язма гариза буенча кире кайтарылырга мөмкин. Әлеге вакыт чыкканчы документлар Кукмара муниципаль районы Советы архивында саклана, шуннан соң алар юкка чыгарылырга тиеш. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тәкъдим ителгән документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

1.10. Конкурста катнашу (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынны наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б.) белән бәйле чыгымнар кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

## II. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм эш тәртибе

2.1. Конкурсларны үткәрү өчен, Кукмара муниципаль районы Советы карары белән даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе оештырыла.

2.2. Конкурс комиссиясе рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм комиссия әгъзаларыннан тора. Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саны 9 кеше тәшкил итә.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, аның хокукларын һәм вазыйфаларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе секретаре комиссия эшен (гаризалар кабул итү, эшләр формалаштыру, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерү һ.б.) тәэмин итә.

2.4. Конкурс комиссиясе составына Кукмара муниципаль районы Башлыгы урынбасары һәм (яки) аның тарафыннан вәкаләт бирелгән муниципаль хезмәткәрләр (шул исәптән кадрлар һәм юридик хезмәттән), Кукмара муниципаль районының Иҗтимагый советы вәкилләре, шулай ук бәйсез экспертлар – муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәләрендә һәм төрләрендә белгечләр булып торучы фәнни, белем бирү һәм башка оешмалар вәкилләре керә.

Кукмара муниципаль районы Иҗтимагый советы һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.

2.5. Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле вазыйфаи бурычларны үтәү белән бәйле муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе за-

коннары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе составы, конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыклары барлыкка килү мөмкинлеге булмаслык итеп төзелә.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына кимендә ике кандидат булса уздырыла һәм, аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче әгъзалар катнашында гына уздыру рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе кандидат белән турыдан-туры шәхси әңгәмә үткәрмичә генә конкурс комиссиясе тарафыннан конкурста җиңүчене билгеләү турында карар кабул итү рөхсәт ителми.

Конкурс комиссиясе тарафыннан, мондый карарның сәбәбен (нигезләнешен) күрсәтеп, аның әгъзасы яисә кандидаты тәкъдиме буенча, видеоконференция форматында (техник мөмкинлек булганда) утырыш уздыру турында карар кабул ителергә мөмкин.

2.9. Конкурс комиссиясе карары кандидат булмаганда кабул ителә.

2.10. Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

2.11. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс йомгаклары буенча комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә конкурс комиссиясе карары белән рәсмиләштерелә. Әлеге карарда кандидатларның конкурс комиссиясе бәяләве нәтиҗәләре буенча җыйган баллары һәм алар биләгән урыннар күрсәтелгән рейтингы була.

2.12. Конкурс комиссиясе эшен оештыруны һәм тәэмин итүне Кукмара муниципаль районы Советы гамәлгә ашыра.

## III. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста катнашуга муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларга карата таләпләргә туры килә торган һәм әлеге Нигезләмәнең 3.7 пунктында каралган срокта әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган гражданнар кертелә.

3.2. Граждан (муниципаль хезмәткәр) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә квалификация таләпләренә туры килмәвенә, шулай ук Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә конкурста катнашырга кертелми.

3.3. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларга карата таләпләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы законнары нигезендә билгеләнгән.

3.4. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы конкурс комиссиясенә түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә форма буенча шәхси гариза;

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тутырылган һәм имзаланган анкета, фотография белән;

паспорт яки аны алмаштыра торган документ күчермәсе (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән тапшырыла);

кирәкле һөнәри белем, квалификацияне һәм эш стажын раслый торган документлар:

хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар, һәм (яисә) гражданның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслый торган башка документлар (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче тапкыр гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш);

белем һәм квалификация турында документлар күчермәләре, шулай ук граждан теләге буенча өстәмә һөнәри белем бирү нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки тапшыруны раслый торган документлар күчермәләре, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турында хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган документлар күчермәләре;

гражданның граждан хезмәтенә керүгә яки аны узуга комачаулаый торган авыруы булмавы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге 984н номерлы боерыгы белән расланган 001-ДС/у исәпкә алу формасы);

Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.

3.5. Җирлекнең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче һәм конкурста катнашырга теләк белдергән муниципаль хезмәткәр әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә форма буенча бары тик шәхси гариза гына тапшыра.

3.6. Граждан (муниципаль хезмәткәр) ризалыгы белән, әгәр граждан (муниципаль хезмәткәр) дәгъвалый торган муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү шундый белешмәләрне куллану белән бәйле булса, дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләргә аны кертү процедурасы үткәрелә.

Граждан биргән белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә бирелгән белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган тикшерүгә дучар ителә.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында күрсәтелгән документлар, аларны кабул итү турында белдерү «Россия Федерациясе дәүләт муниципаль хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасының (алга таба – Федераль мәгълүмат системасы) рәсми сайтында урнаштырылганнан соң 21 календарь көн эчендә конкурс комиссиясенә граждан (муниципаль хезмәткәр) тарафыннан шәхсән, почта аша яисә электрон рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә федераль мәгълүмат системасын кулланып, җибәрелә.

Документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яки җитди сәбәпсез рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданнан (муниципаль хезмәткәрдән) аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

## IV. Бәйгене үткәрү методикасы

4.1. Конкурсларны үткәрүгә әзерлек кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларын (алга таба – бәяләү методлары) сайлап алуны һәм аларга туры килә торган конкурс биремнәрен формалаштыруны, кирәк булганда, муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларына карата конкурс игълан итү планлаштырыла торган муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларына карата муниципаль хезмәткәрләрнең

вазыйфаи инструкцияләре нигезләмәләрен актуальләштерүне күздә тота.

4.2. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләре нигезләмәләрен актуальләштерү, бәяләү методларын сайлау һәм аларга туры килгән конкурс биремнәрен формалаштыру Җирлекнең кызыксынган җирле үзидарә органы бүлекчәләре тарафыннан башкарыла. Конкурс комиссиясе әгъзалары бәяләү методларын куллану һәм конкурс биремнәрен формалаштыру турында тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

Җирлекнең җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләрендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларына карата конкрет белгечлеккә (әзерлек юнәлешенә) карата квалификация таләпләре билгеләнергә мөмкин.

4.3. Кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның квалификация таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү өчен, конкурс процедуралары барышында федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган бәяләү методлары, индивидуаль әңгәмә, муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча тест уздыру да кулланылырга мөмкин.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.5. Беренче этапта Кукмара муниципаль районы советының кадрлар хезмәте түбәндәгеләрне оештыра:

Кукмара муниципаль районы һәм Федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтларында конкурс үткәрү турында мәгълүмат әзерләү һәм урнаштыру: муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы атамасы, әлеге вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре, муниципаль хезмәт узу шартлары, муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә кандидатлар бирә торган документлар һәм материаллар исемлеге нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, әлеге документлар кабул ителә торган вакыт, конкурсны үткәрү өчен күз алдында тотылган көн, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, бәяләү методлары турында белешмәләр, муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын, хокукларын һәм вазыйфаи бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җаваплылыкны үз эченә алган вазыйфаи инструкциясе нигезләмәләре, башка мәгълүмати материаллар;

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерү;

гражданның (муниципаль хезмәткәрнең) квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү (һөнәри белем дәрәҗәсе, муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек буенча эш стажы (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле һөнәри белем һәм күнекмәләре).

4.6. Тикшерү барышында Федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә гражданның муниципаль хезмәткә керүенә комачаулаучы хәлләр ачыкланганда, аңа Кукмара муниципаль районы Советының кадрлар хезмәте тарафыннан конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турында язмача хәбәр ителә. Граждан конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган очракта, конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турында хәбәрнамә аңа көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән, федераль мәгълүмат системасын кулланып, электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.7. Конкурста катнашуга кертелмәгән вакантлы вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы әлеге карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

4.8. Конкурсның беренче этабын тәмамлау шарты булып, муниципаль хезмәтнең билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килә торган бер вакантлы вазыйфасына ике кандидатның булуы тора, бу исә кандидатларны киләчәктә сайлап алу мөмкинлеген

тәэмин итә.

Кандидатлар булмаса яки вазыйфага карата квалификация таләпләренә туры килгән бер генә кандидат булса, конкурс узмаган дип танылa. Бу очракта бердәнбер кандидатка кандидатларның таләп ителә торган саны булмау сәбәпле, конкурс үткәрелмәгән дип хәбәр ителә.

4.9. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач, Кукмара муниципаль районы Башлыгы конкурсның икенче этабын үткәрү датасы (катнашу өчен документларны кабул итү тәмамланганнан соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләргә рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта, конкурсның икенче этабын үткәрү вакытын җирле үзидарә органы җитәкчесе билгели.

Кукмара муниципаль районы Советының кадрлар хезмәте конкурсның икенче этабы башланганчы 15 календарь көннән дә соңга калмыйча Кукмара муниципаль районы һәм Федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтларында аны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, конкурста катнашырга рөхсәт ителгән кандидатлар исемлеген урнаштыра һәм кандидатларга язма рәвештә, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга - көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, федераль мәгълүмат системасын кулланып хәбәр җибәрә.

4.10. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

«Татарстан Республикасы дәүләт муниципаль хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кандидатлар турында мәгълүмат кертү (алга таба – Бердәм мәгълүмати кадрлар системасы);

кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү;

муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе тарафыннан карар кабул итү;

Бердәм мәгълүмати кадрлар системасында конкурс нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

конкурс нәтиҗәләрен Кукмара муниципаль районы һәм Федераль мәгълүмат системасы сайтларында бастырып чыгару.

4.11. Конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе кандидатларны белеме, муниципаль яки дәүләт хезмәтен узу, башка хезмәт эшчәнлеген тормышка ашыру турындагы алар тапшырган документлар нигезендә, шулай ук тест, шәхси әңгәмәне үз эченә ала торган бәяләү методларын кулланып, конкурс процедуралары нәтиҗәләре нигезендә бәяли.

Кукмара муниципаль районы Советы тарафыннан конкурс комиссиясе эшчәнлеге, шулай ук кандидатлар тарафыннан конкурс процедураларын узу өчен тиешле оештыру һәм матди-техник шартлар тудырыла.

4.11.1. Тест аша дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә кандидатларның Россия Федерациясе дәүләт телен (рус телен) белү, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләрен, муниципаль хезмәт турында һәм коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын белү, мәгълүмати-коммуникацион технологияләр өлкәсендә белем һәм күнекмәләре, шулай ук һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә карап белем һәм осталыклары дәрәҗәсен бәяләү гамәлгә ашырыла,

4.11.2. Кандидатлар белән шәхси әңгәмә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан үткәрелә.

Шәхси әңгәмә кысаларында кандидатның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүгә юнәлдерелгән

сораулар бирелә.

Бу максатларда, муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны исәпкә алып, муниципаль хезмәтнең һәр вакантлы вазыйфасы буенча сораулар исемлеге төзелә. Сораулар исемлеге комиссия утырышына муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелә торган структур бүлекчә җитәкчесе тарафыннан әзерләнә.

Кандидат белән шәхсән әңгәмә тәмамланганнан соң, конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы нигезендә форма буенча төзелә торган конкурс бюллетеньенә кандидатны бәяләү нәтиҗәләрен кертә.

Шәхси әңгәмә нәтиҗәләре буенча кандидат 0 дән10 га кадәр балл алырга мөмкин.

4.12. Кандидатның йомгаклау баллы шәхси әңгәмә нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кандидатка куелган балларның һәм тест нәтиҗәләре буенча кандидат җыйган балларның уртача арифметик суммасы буларак билгеләнә.

Кандидатларның йомгаклау балларын чагыштыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе секретаре аларның йомгаклау балларының кимүе тәртибендә кандидатлар рейтингын формалаштыра.

4.13. Конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып, конкурс комиссиясенең әлеге Нигезләмәнең 2.11 пунктында күрсәтелгән карар бланкына яисә конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе бланкына кертелгән карары тора.

4.14. Әгәр конкурс үткәрү нәтиҗәсендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы буенча барлык таләпләргә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, конкурс комиссиясе конкурста җиңүче билгеләнмәгән дигән карар кабул итә.

4.15. Конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрләр, аны тәмамлаганнан соң җиде көн эчендә, кандидатларга язма рәвештә, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга - көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, федераль мәгълүмат системасын кулланып җибәрелә. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шушы ук вакытта Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында, Федераль мәгълүмат системасында һәм Бердәм мәгълүмати кадрлар системасында урнаштырыла.

Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрү турындагы
Нигезләмәгә 1 нче кушымта

# МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТНЕҢ ВАКАНТЛЫ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮГӘ КОНКУРС ЙОМГАКЛАРЫ БУЕНЧА КОНКУРС КОМИССИЯСЕ КАРАРЫ

«__» ____________ 20__ ел

конкурсны үткәрү датасы

Конкурс комиссиясе утырышында _____ конкурс комиссиясе әгъзасының _____ катнашты:

Комиссия рәисе: ____________________________

фамилиясе, инициаллары

Конкурс комиссиясе секретаре: ____________________________

фамилиясе, инициаллары

Конкурс комиссиясе әгъзалары: ____________________________

фамилиясе, инициаллары

____________________________

фамилиясе, инициаллары

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелде

______________________________________________________________

вазыйфаның, структур бүлекчәнең атамасы

______________________________________________________________

Кандидатларны рейтинг бәяләү нәтиҗәләре:

| Кандидатның ФИА | Йомгаклау баллы | Рейтингта урын (кимү тәртибендә) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

Конкурсның җиңүчесен билгеләү буенча тавыш бирү нәтиҗәләре (барлык кандидатлар буенча тутырыла):

| ____________________________ Рейтингта беренче урынны алган кандидатның ФИА | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының ФИА | Тавыш бирү | | |
| | «риза» | «каршы» | «тыелып калдылар» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |

| Рейтингта икенче урынны алган кандидатның ФИА | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының ФИА | Тавыш бирү | | |
| | «риза» | «каршы» | «тыелып калдылар» |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |

| Рейтингта өченче урынны алган кандидатның ФИА | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының ФИА | Тавыш бирү | | |
| | «риза» | «каршы» | «тыелып калдылар» |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |

Тавыш бирү нәтиҗәләренә шәрехләр (кирәк булганда) ______________________________

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе конкурсның җиңүчесе дип таный

_____________________________________________________________________________

Кандидатның ФИА

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелде

_____________________________________________________________________________

вазыйфаның, структур бүлекчәнең атамасы

Кандидатларны рейтинг бәяләү нәтиҗәләре:

| Кандидатның ФИА | Йомгаклау баллы | Рейтингта урын (кимү тәртибендә) |
|---|---|---|
| | | |

Конкурсның җиңүчесен билгеләү буенча тавыш бирү нәтиҗәләре (барлык кандидатлар буенча тутырыла):

| Рейтингта беренче урынны алган кандидатның ФИА | |
|---|---|
| Конкурс комиссия- | Тавыш бирү |

| се әгъзасының ФИА | «риза» | «каршы» | «тыелып калды-лар» |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |

| ___ Рейтингта икенче урынны алган кандидатның ФИА | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссия-се әгъзасының ФИА | Тавыш бирү | | |
| | «риза» | «каршы» | «тыелып калды-лар» |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |

| ___ Рейтингта өченче урынны алган кандидатның ФИА | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссия-се әгъзасының ФИА | Тавыш бирү | | |
| | «риза» | «каршы» | «тыелып калды-лар» |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |

Тавыш бирү нәтиҗәләренә шәрехләр (кирәк булганда) ______________________

________________________________________________

________________________________________________

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе конкурсның җиңүчесе дип таный

________________________________________________

Кандидатның ФИА

Комиссия рәисе: ____________ ______________________

(имза) фамилия, инициаллар

Конкурс комиссиясе секретаре: ____________ ______________________

(имза) фамилия, инициаллар

Конкурс комиссиясе әгъзалары: ____________ ______________________

(имза) фамилия, инициаллар

Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәгә 2 нче кушымта

_____________________________________
(җитәкченең вазыйфасы, инициаллары, фамилиясе)
_____________________________________
(гариза бирүченең фамилиясе,
_____________________________________
исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)
_____________________________________
(яшәү адресы,
_____________________________________
гариза биргән вакыттагы эш урыны,
_____________________________________
вазыйфасы)
_____________________________________
(кесә телефоны,
_____________________________________
электрон почта адресы)

Гариза

Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурста катнашуга үткәрүегезне сорыйм:
_____________________________________________________________________
(вакантлы вазыйфаның һәм бүлекчәнең исеме)

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турында кодексы, Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы Нигезләмә белән, шул исәптән вакантлы вазыйфаны биләү өчен куела торган квалификация таләпләре белән таныштым.

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза.

e-mail яки күрсәтелгән кәрәзле телефон номерына СМС-хәбәрләр аша бәяләү методлары, конкурсның датасы һәм урыны, тәртибе һәм нәтиҗәләре турында хәбәр итүгә килешәм.

Гаризага кушымта итеп бирәм:
_____________________________________________________________________
(кушымта итеп бирелә торган документларны санап чыгарга)
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________

_______________ _______________ _______________
(дата) (имза) (имзаның расшифровкасы)

_______________ _______________

Вакантлы вазыйфаны биләүгә
конкурс үткәрү турындагы
Нигезләмәгә 3 нче кушымта

КОНКУРС БЮЛЛЕТЕНЕ
«__» ____________ 20__ ел

1.______________________________________________________________
биләүгә конкурс үткәрелә торган вазыйфаның атамасы
________________________________________________________________
яки кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелә торган вазыйфалар төркеме атамасы
________________________________________________________________

Конкурс комиссиясе әгъзасы тарафыннан кандидатларга шәхси әңгәмә нәтиҗәләре буенча бирелә торган баллар (иң югары балл – 10 балл).

| Кандидатның ФИА | Балл | Куелган балның кыскача дәлилләре (кирәк булганда) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

2.______________________________________________________________
биләүгә конкурс үткәрелә торган вазыйфаның атамасы
________________________________________________________________

Конкурс комиссиясе әгъзасы тарафыннан кандидатларга шәхси әңгәмә нәтиҗәләре буенча бирелә торган баллар (иң югары балл – 10 балл).

| Кандидатның ФИА | Балл | Куелган балның кыскача дәлилләре (кирәк булганда) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

________________________________________ ____________
Конкурс комиссиясе әгъзасының ФИА имза

________________________________________________________________